«АКЫЛЛЫ» ШӘҺӘР, САНЛЫ АВЫЛ

Цифрлаштыру елының максатлары билгеле

> 2

ИЛ АГАСЫ

Халык шагыйре Разил Вәлиевнең Беренче Президент турында истәлекләре

> 3

САКЛАГАННЫ ЯРАТА

Ни өчен бездә тарихи романнар кытлыгы?

> 3

БИТТӘ – КЕРШӘН, КҮЗДӘ – СӨРМӘ

Бизәнеп йөрүче ирләр күбәйде

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 7 (28780) | Чәршәмбе | 19 гыйнвар | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

КЕСӘДӘ АКЧА БУЛУ РӘХӘТ

Шөгыль

«Әнидән акча сорыйсы килми». Техникум, вузларда укып эшләүче студентлар әнә шулай ди. Тик ятарга теләмәгән кешегә беркайчан да эш бетми. Яшьләр арасында лекциядән соң чәчәк сатучы, тырнак-керфек ясаучы, фотога төшерүче, йөк ташучы, өйгә ризык илтүчеләр бар. Укуга зыян китермәгән эшне кайдан табарга?

Яшьләргә эш табу җиңеләеп китмәгәе. Россия Хезмәт министрлыгы мәшгульлек үзәкләре өчен студентларны вакытлыча эшкә урнаштыру буенча стандарт әзерләгән. Бу шулай ук кулында дипломы булган 18–25 яшьлек студентларга да кагыла. Шул ук вакытта 14–18 яшьлек үсмерләр дә буш вакытларында эш сорап мөрәҗәгать итә ала.

– Вакытлыча эшкә урнаштыру укыган һөнәрең буенча үзеңне сынап карау, тәҗрибә туплау мөмкинлеге бирә. Мәшгульлек үзәкләрендә моңа кадәр андый хезмәт бар иде, тик ул урта һөнәри уку йортын тәмамлаган 18–20 яшьлек үсмерләргә кагылды. Хәзер яшь чиге үзгәртелде. Моның өчен «Работа России» порталында гариза язарга кирәк. Бернинди документлар җыю да таләп ителми. Мәшгульлек үзәкләре оешмаларга туры килердәй яшьләрне сайлап алачак, – дип ачыклык кертә Россия хезмәт министры урынбасары Елена Мухтиярова.

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү, социаль яклау министрлыгының матбугат үзәгеннән алынган мәгълүматларга караганда, мәшгульлек үзәкләре аша узган ел 13177 үсмер эшкә урнаштырылган. Алар мәктәпләр, спорт мәйданчыкларын төзекләндерү, тирә-якны яшелләндерү, елга буйларын чистарту, урманнарны чүптән арындыру кебек эшләрдә катнашкан. Әлегә быел күпме үсмернең эшкә урнашуы турында мәгълүмат юк. Ни өчен дигәндә, «2014–2025 елларда Татарстанда халыкны эшкә урнаштыруга ярдәм итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертелмәгән.

Студентлар ыштан туздырып кына йөрми. Күбесе укырга да, эшләргә дә вакыт таба.

– Эшне интернеттагы төрле төркемнәрдән эзлим. Анда нинди генә белдерү юк бит. Гадәттә, эшне сәгатьләп тәкъдим итәләр. Мин үзем йөк ташыйм. Бер сәгатькә 250–500 сум түлиләр. Кайвакыт авыр әйберләрне дә югары катларга күтәреп менгезергә туры килә. Әлбәттә, моның өчен сәламәтлек тә кирәк. Шабашкага лекциядән соң атнага өч мәртәбә баргалыйм. Тәмлерәк ашыйсы, киногада барасы килә. Кесә чыгымнары өчен әнидән акча сорарга оялам. Студентка акча беркайчан да җитми инде аңа. Кесәдә акча булгач, рәхәт, – ди Казанның төзелеш техникумы студенты Илназ Шәрәпов.

КФУ студентлары да вакытларын бушка уздырмый. Инглиз теле белгечлеге буенча укучы Айгөл дә сабакташлары белән кесәлек акча эшли икән.

– Һәр студент ничек тә булса акча эшләү юлын эзли. Бер яктан, мөстәкыйль яшәргә тырышу теләге булса, икенчедән, әти-әнидән акча алу әллә ничек кыен шунда. Киләчәктә репетитор булып эшләргә исәп. Әлегә яхшылап белем туплыйм. Буш вакытта табак-савыт, идән юабыз, кунакханә бүлмәләрен җыештырабыз, чишенү бүлмәсендә киемнәр бireп торабыз. Җаен «Макдоналдс»та эшләгән күп кенә студентларны беләм. Яшьләрне юкка ялкау дип сүгәләр. Чынбарлыкта алай түгел, – ди Айгөл.

Акчаны сәгатенә карап түлиләр, ди. Әйтик, иртәнге сәгать 8дән кичке 8гә кадәр табак-савыт юу бәясе – 1000–1200 сум. «Тик без көн буе эшли алмыйбыз, укырга барасы бар. Бүлмә җыештырып, ярты тәүлеккә 1300 сум алырга мөмкин. Көн буе кием биреп тору хакы – 1000 сум. Кайбер эшләрдә QR-код һәм медицина белешмәсе сорыйлар», – дип сөйләде Айгөл.

Алинә Салихова вузда реклама белгечлеге ала. «Интернетта да акча эшләү мөмкинлекләре зур. Мин социаль челтәрләрдә берничә сәхифә алып барам. SMM буенча курсларны тәмамладым. Хәзер бу эшкә көнгә берничә сәгать вакыт китә. Шунысы рәхәт: атнага кесәгә 5–8 мең сум акча керә», – ди Алинә.

Күптән түгел журналист Алсу Исмәгыйлева «Инстаграм» сәхифәсендә күңелгә үтәрлек бер пост куйган иде.

«Миндә яңа халәт. Улым Самат җәяүле курьер булып эшкә урнашты. Ялларда тәмле әйберләр пешереп, улымны ашатып, эшкә озату – яңа халәтем. Әйе, мин бу хакта горурланып язам. Баланы бит горурланырлык итеп үстерәсе килә. Улыбыз эшләргә карар кылган икән, димәк, хыял-максатлары бар. Ә тагын… Ә тагын мин кеше балаларына яңача карый башладым. Мин дә ризык китертү хезмәтеннән файдаланам, безгә дә студент егетләр һәм кызлар нәрсәләрнедер өйгә китереп бирә. Элек аларга күтәрелеп тә карамыйча, кулларыннан пакетны алып, тизрәк борылып китә идем, ашыгабыз бит. Ә хәзер күзләренә карыйм. Алар да – кемнеңдер балалары. Аларны да эшкә хыял-максатлары китергән. Шуңа күрә мактыйм, чәйлек акча да калдырам. «Чәйлекләр калдырмадылар әле», – ди Самат. «Мин кеше балаларын ныграк хөрмәтләгән саен, сиңа да хөрмәт артыр, улым», – дип уйлыйм. Үзенә әйтмим», – дип язган ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ахыры 2 нче биттә >

Мәчет өчен урын тәгаенләнә

Казанда Җәмигъ мәчетен төзү өчен берничә урын карала. «Бу мәсьәлә кирәкле барлык тикшеренүләр һәм килештерүләрдән соң гына хәл ителәчәк», – дигән Татарстан Президенты матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Галимова «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгына.

Мәчет төзү өчен Казансу елгасының уң як яры буенда Кырлай паркы тирәсендәге, Бишбалта бистәсендә ком базасы тирәсендәге җирләр, Киров районының Шоссе урамында яр буе мәйданчыгы һәм башка вариантлар карала. «Татарстан Президенты кирәкле барлык экологик тикшеренүләр һәм шәһәр төзелеше буенча килештерүләр үткәрү бурычын куйды. Шуннан соң гына Җәмигъ мәчетен төзү урыны турында ахыргы карар кабул ителәчәк», – дип белдергән Галимова.

13 гыйнварда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов мәчетне Казансу елгасының уң яры буенда төзү нияте барлыгын әйткән иде.

Җир җитми

Казанда күпбалалы гаиләләргә бирү өчен 9 меңнән артыграк җир кишәрлеге җитми. Республикада 66 меңгә якын шундый гаилә җир кишәрлеген алучылар исемлегенә кертелгән. 42 меңе кишәрлекне алган. Шул ук вакытта Татарстан башкаласында яңа җир кишәрлекләренә бик зур ихтыяҗ саклана. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры Фәнил Әһлиуллин белдергәнчә, Сокуры һәм Каймар бистәләрендә муниципаль җирләр бүленеп беткән. Хәзерге вакытта федераль җирләрне үзләштерү эше дәвам итә.

Чаллыда 58 меңнән артыграк кишәрлек җитми. Хәзер Тукай районы Калмаш авыл җирлегендә урнашкан җирләр күпбалалы гаиләләргә бирү өчен әзерләнә.

Моннан тыш Бөгелмә, Яшел Үзән, Лениногорск, Әлмәт, Баулы, Кукмара, Лаеш һәм Түбән Кама районнарында күпбалалы гаиләләрнең 80 процент чамасы гына җирле булган.

Узган елда Татарстанда күпбалалы гаиләләргә барлыгы 3838 кишәрлек бирелгән.

Саклык акча арта

Татарстан халкы банкларда 712 миллиард сумга якын акча саклый (торак төзү өчен ачылган эскроу-счетлардагы акчаны кертеп). Бу – алдагы елдагыга караганда 10,8 процентка күбрәк, дип хәбәр итә Россия Банкының республика буенча бүлеге матбугат хезмәте.

Республикада сумнарда сакланылучы акча өлеше банклардагы барлык саклык акчаның 84,2 процентын тәшкил итә (599,3 миллиард сум). Бер ел эчендә сумның өлеше 8,9 процентка арткан. Чит ил валютасындагы саклык акча күләме 22,1 процентка үсеп, 112,6 миллиард сум тәшкил иткән.

Юридик затларның депозиттагы акча күләме исә 2020 елның шушы ук чоры белән чагыштырганда 32,3 процентка үсеп, 534 миллиард сумга җиткән. Хосусый эшмәкәрләрнең акчасы 19,6 процентка артып, 21,4 миллиард сум булган.

COVID – 19

Саннар сагайта

«ОМИКРОН» ТАТАРСТАНГА ДА КИЛЕП ҖИТТЕ

«Омикрон» Россия буенча таралды. Татарстанда аны 11 кеше йоктырган. Коронавируска каршы көрәш буенча координацион совет президиумы утырышында Россия Хөкүмәте җитәкчесе Михаил Мишустин төбәкләр җитәкчеләренә чиргә каршы эшчәнлекне көчәйтергә кушты.

– Бу медицина учреждениеләре, «ашыгыч ярдәм» хезмәте эшчәнлеген оештыруга, «кайнар элемтә» булдыру, студентларны, волонтерларны җәлеп итүгә кагыла. Кешеләрнең тормышын кайгырту өчен, хәлдән килгәннең барысын да эшләргә кирәк, – диде ул.

Хөкүмәт башлыгы, инфекция таралуны булдырмас өчен, өстәмә чаралар күрүнең, кирәкле күләмдә дарулар запасын тәэмин итү, коронавируска каршы тест уздыру, халык мөрәҗәгатьләренә вакытында җавап бирүнең әһәмиятен искәртте.

Россия Президенты боеруы буенча, авыручылар саны кискен арткан очракта сәламәтлек саклау тармагына ярдәм итәргә тиешле өстәмә чаралар планы әзерләнгән. Аның күп өлеше медицина оешмаларына кагыла.

– Иң элек сүз сәламәтлек саклау инфраструктурасының әзерлеге хакында бара. Беренчел звеноны әзерләү мөһим. Штаммның үзенчәлеге дә шунда: авырлык амбулатор тармакка төшәчәк. Төбәкләргә дарулар сатып алуга 5 млрд сум акча бүлеп биреләчәк. Тест уздыруны арттырырга кирәк. Санитар таләпләр үтәлешен тикшерүне контрольгә алу зарур, – диде Хөкүмәт башлыгы.

Сәламәтлек саклау тармагына эшне киметү һәм табибларга пандемиягә каршы көрәштә ярдәм итү өчен, мөмкин кадәр күбрәк кеше читтән торып эшләсә әйбәт. «Эш бирүчеләргә мөрәҗәгать итәм: хезмәткәрләрне читтән торып эшләүгә күчерергә кирәк. Беренче чиратта бу өлкән яшьтәгеләргә һәм хроник чирләре булган кешеләргә кагыла», – диде Михаил Мишустин. Читтән торып эшләүгә күчмәгән хезмәткәрләр өчен исә даими рәвештә коронавируска каршы тест тапшыруны оештыру зарур.

Вице-премьер Татьяна Голикова чыгышыннан аңлашылганча, Россиядә «омикрон» йоктыручылар саны 1682 кешегә җиткән. Штамм илнең яртысын диярлек чолгап алган инде. Россия буенча «дельта» штаммын йоктыручылар күрсәткече – 60, «омикрон» – 40 процент. «Омикрон» йоктыручыларның 27,9 проценты гына вакцина ясаткан булган.

Бу җәһәттән Михаил Мишустин вакциналаштыруның мөһимлеге турында да әйтте. «Вакытында вакциналаштыру һәм авыруның кискенләшүенә юл куймау өчен, кабат прививка кадатырга кирәклеген барлык белгечләр дә искәртә», – диде ул.

САН

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, Татарстанда «омикрон» штаммының **11** очрагы теркәлгән. **4** очрак – Россия төбәкләреннән, **биш**есе чит илләрдән кайткан кешеләрдә ачыкланган. **Сигез** кешедә ОРВИ билгеләре күзәтелә, **өч**есе чирне симптомнарсыз гына кичерә.

Россиядә күмәк иммунитет дәрәҗәсе **63,9** процентка җиткән. Севастополь, Санкт-Петербург, Карелия һәм Чукотка автономияле округында ул **80** процентны тәшкил итә.

Сүзгә-сүз

«Татар-информ»

Артур ПИСАРЕНКО, каллиграф:

Мине һәрвакыт бер нәрсә борчый иде: без, татарлар, Коръән укыйбыз. Ләкин шул ук вакытта үзебезнең кулъязмабыз юк. Балачакта каяндыр алып кайтылган Коръәнне укый идем, тик безнекеләр иске, каллиграфиядәге алгарышларны һәм соңгы гасырлардагы китап бастыру алымнарын исәпкә алмыйча эшләнгән.

(«Реальное время» басмасына биргән әңгәмәсеннән)

ЧЫГЫМ КҮЛӘМЕ ҮЗГӘРДЕМЕ?

Пандемия чорында Россиядә яшәүчеләрнең яртысы диярлек акчасын саграк тота башлаган һәм чыгымнарын киметкән. «SuperJob» хезмәте уздырган сораштыру нәтиҗәләре шуны дәлилли.

ЧЫГЫМНАР КИМЕДЕМЕ?

Күп нәрсәдә үземне чиклим	47%
Керем һәм чыгымнарда үзгәреш сизмәдем	33%
Сәламәтлеккә һәм шәхси ихтыяҗларга күп акча китә	10%



КЕМНӘР КҮБРӘК ЭКОНОМИЯЛИ?

Хатын-кызлар	46%
Ир-атлар	42%

Төрмәдән чыкмаячак

Дәүләт Думасы педофилларга гомерлек төрмә җәзасы бирү турында законны икенче укылышта кабул иткән. Гомерлек төрмә җәзасы баланы мыскыл иткән өчен төрмәдә утырып чыккан җинаятьчеләргә (педофил-рецидивистларга) яный. Шулай ук бала үстерүче, мәгариф өлкәсендә эшләүче педофилларга, җинаять өчен дәгъва вакыты чыкса да, җәза чарасын кырысландыру тәкъдимнәре карала.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ВУЛКАН АТКАН КЕБЕК

Үткән атна ахырында, 15 гыйнвар көнне, Тын океандагы Полинезиядә тарихтагы иң көчле вулкан атуларның берсе булды. Белгечләр исәпләвенчә, көл баганасы 20 километрга кадәр биеклеккә күтәрелде һәм тропосфераны үтеп чыкты. Вулкан активлыгы шкаласы буенча Хунга-Тонга вулканы атылуы 8 мөмкинлектән 7 балл белән бәяләнде. Билгеләп үтик: соңгы 2000 ел эчендә, ягъни безнең эрада бер генә вулкан ату да 8 балл белән бәяләнмәгән. Галимнәр көл баганасы тагын 2 километрга күтәрелгән булса, планета бер елга җәйсез кала иде дигән фараз әйтәләр. Шул хәлендә дә Көньяк һәм Төньяк Америкада, Япония, Австралия һәм Яңа Зеландия ярларында цунами китереп чыгарган бу шартлау Җир шарының глобаль суынуына китерергә ихтимал дигән фараз белдерүчеләр бар. Әмма инде хәзер әйтергә мөмкин: планета зур катастрофадан котылып калды.

Дөньяда исә социаль шартлаулар һәм сәяси конфликтлар безнең иминлеккә вулкан атуы кебек үк яныйлар. Төрле төбәкләрдә сугыш хәрәкәтләре дәвам итә, зур державалар арасында дөньякүләм конфликтларның алшартлары төенләнүдән туктамый. Икътисад та үзен зур шартлау алдындагы кебек тота. Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә Әбу-Даби шәһәренә дроннар һөҗүм итте. Өч кеше үлде, 6 кеше яраланды дигән рәсми хәбәрләр бар. Һөҗүм өчен җаваплылыкны үз өсләренә Йәмән гыйсъянчылары алды. Гарәбстан ярымутравы инде озак еллар буе бетми һәм тынмый торган ярымсугыш халәтендә яшәвен дәвам итә.

Украина тирәсендәге киеренкелек тә әле һаман зур конфликт белән яный. Киев лидеры Зеленский Байден һәм Путинны өчьяклы күзгә-күз сөйләшүгә чакырды. Әлегә Мәскәү һәм Вашингтонның җавабы билгесез, әмма сөйләшү омтылышы начар түгел инде ул. Россия илчелеге Киевтагы үз персоналын эвакуацияли дигән хәбәрләр бар. Дипломатларның гаилә әгъзалары илгә кайтып китә икән. Монысы – начар хәбәр, димәк, киеренкелек куркыныч. Украинаның элекке Президенты Петр Порошенко илгә кайтты. Аңа җинаять эше ачылган иде, хәзер суд аны тоткарлау мәсьәләсен карый, ләкин хәл итә алмый әле. Порошенко исә үзен тыныч тота, төрмәгә утырмаячагына ышана. Суд залында ул Зеленскийны наркотиклар кулланудан тукталырга өндәде: «Сезнең идеяләрегез абсолют дәрәҗәдә адекват түгел», – дип белдерде. Порошенко яклылар мәйданнарда җыела. Куркыныч вазгыять бу, чөнки конфликтның көтелмәгән борылыш ясавы бар.

Дөнья икътисадында да хәлләр шулайрак. Кытай лидеры Си Цзиньпин дөнья икътисадының кризистан чыгып килүен, әмма бу юлда зур кыенлыклар барлыгын игълан итте. Кытай хакимиятләре гражданнарны чит ил товарларын сатып алмаска өндиләр, моны чир таралу куркынычы белән аңлаталар. Гомумән, статистикага карасак, икътисадта кризистан чыгу түгел, вулкан ату халәте күзәтелә. Әйтик, Польшада, газ бәясе югары булу сәбәпле, предприятиеләр ябыла. Дистә еллар буе уңышлы эшләп килгән предприятиеләр, газга бәя 800 процентка артты дип, ишекләренә йозак эләләр.

Россиядә

ЗАКОН ПРОЕКТЫН – ЧҮПЛЕККӘ

Дәүләт Думасында инде «сакаллы»га әверелә башлаган QR-кодлар турындагы законны караудан алдылар. Коронавирус белән бәйле чикләүләрнең «җимеше» булырга тиешле бу законга Россия җитәкчелеге бик сак карады һәм акыл белән эш итәргә тырышты. Көнбатыш демократияләрендә бу мәсьәләдә әнә тулысынча диктатура урнашып бара. Вакцина ясатуны мәҗбүри итүче, аннан баш тартучыларга саллы штрафлар кертүче илләр бар. Әмма ул диктатураның нәтиҗәсе бер дә уңай түгел: чир барыбер рекордлы темплар белән тарала, икътисад исә күрелгән чаралар катылыгы астында сыгылып килә. Россия Президенты Владимир Путин бу мәсьәләдә һәрвакытта да уртачыл караштa торды. Вакциналаштыруның ирекле булуын ассызыклаган хәлдә халыкны аны ихтыярый рәвештә ясатырга өндәде. QR-кодлар турындагы законны да инде беренче укылыштан соң, Дума өстәленнән алып, йомшартырга, гражданнарның хокукларын сакларга өндәүче дә Путин булды.

Канун проекты Думага ноябрь аенда Хөкүмәт тарафыннан кертелгән иде. Башта аны тизләтелгән режимда карарга һәм кабул итәргә теләделәр. Әмма, бизнес вәкилләре тәэсире нәтиҗәсендә дип уйлыйк, беренче укылыш бер айга чигерелде. Икенче укылыш 15 гыйнварга тәгаенләнгән иде, әмма аны кабат 1 февральгә күчерделәр. Путин әмере белән аны йомшарта, җепшеклек өсти торган төзәтмәләр дә игълан итеп өлгерелде инде. Бу дүшәмбедә Президент сүзчесе Песков исә хәтта төзәтмәләрнең дә кирәк булмаячагын әйтеп: «Хәлгә карап эш итәбез», – диде. Шул ук көнне Дума Рәисе Вячеслав Володин проектның бөтенләй алынуын игълан итте. Думаның барлык фракцияләре дә бу карарны бердәм яклаганнар.

QR-кодлар табигый рәвештә күпчелек халыкның каршылыгына очрады. Бездә халык урамнарга чыгып шауламады, билгеле, әмма Володин «Телеграм»да гражданнарның үз фикерләрен әйтүләрен сорагач, кешеләр гадәттән тыш активлык күрсәтте, 700 меңнән артык комментарий җыелды.

Канун проектының тикшерелүдән алынуы QR-кодларның гамәлдән чыгарылуы дигән сүз түгел ләкин. Төбәк җитәкчеләре, вазгыятькә карап, чикләүләрне кертә дә, туктата да алалар. Федераль Хөкүмәт бу мәсьәләдә төбәкләргә тулы суверенитет бирә, бары шул гына. Вазгыять яхшырыр дип өметләник. Тик якындагы бер-ике ай кызу булыр, мөгаен. «Омикрон»ны сезонлы ОРВИ рәвешендә уздырырга насыйп итсен барыбызга да. Чит илләр тәҗрибәсе шуңа ишарә итә. Җәйгә янә QR-кодларсыз тормыш килер дип ышаныйк һәм Галәмнәрнең Хуҗасыннан шуны сорыйк.

ЧҮПТӘН – ҖЫЛЫЛЫК, АВТОБУС УРЫНЫНА – ЭЛЕКТРОБУС

eco.tatarstan.ru

Нәтиҗә

Узган ел республикада экологиягә кагылышлы дүрт федераль проект тормышка ашырылган. Алар ярдәмендә соңгы өч елда табигатьне 5 млрд сумлык зыяннан саклаганнар. Бу хакта Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков еллык киңәйтелгән утырышта сөйләде.

– «Иделне савыктыру», «Чиста ил», «Уникаль су объектларын саклау», «Урманнарны саклау» федераль проектларын тормышка ашыру өчен 3 млрд 300 миллион сум акча тотылды. Шул исәптән, аның 2,5 млрд сумы федераль бюджеттан бирелде. Әлеге проектлар ярдәме белән соңгы өч елда табигатьне 5 млрд сумлык зыяннан саклaдык, – ди Александр Шадриков. – Табигатькә сакчыл карашны ниндидер суммалар белән бәяләү бик дөрес тә түгел. Без иң элек кешеләргә яшәр өчен уңай мохит булдырырга тиеш. Үткәрелгән экологик чаралар нәтиҗәсендә Татарстанда яшәүче 2 миллион кешенең тормыш шартларын экологик яктан яхшырттык, дип әйтә алабыз.

Быел исә «Экология» илкүләм проекты кысасында бу максатларга 5 млрд 589 миллион сум акча тотылачак. Шуның ярдәмендә еллар дәвамында җыелып килгән проблемаларны хәл итәчәкләр. Киләсе елдан сулыкларга игътибар тагын да артачак.

Министр узган ел башкарган эшләргә дә тукталды. Түбән Кама районының Прости авылындагы халыктан бик күп зар җыйган чүплек урынында чишмә бәреп чыккан. Ә менә Самосырово бистәсендәге чүплектән сасы ис килүдән зарланучылар бар икән әле. Зарланмаслар да иде – әлеге вакытта чүплектә эшләр бара. Аларны башкарыр өчен быел федераль бюджеттан 173 миллион сум акча бирелгән.

– Без ул чүплектән файда алмакчы булабыз. Сасы ис чыгуның сәбәбе чүплектәге эшләргә бәйле. Тиздән ул ис бетәчәк. Киләчәктә аннан чыккан газдан электр энергиясе алачакбыз. 2021 елда без бу эшкә керештек инде. Чүплектән электр энергиясе алу проекты 2023 елда тормышка ашачак. Чүплек бетерелгәч, 350 мең кешенең тормыш сыйфаты яхшырачак, – ди министр.

Ә торбалардагы сулардан җыелган ләм басулары урынында киләчәктә урман үсәчәк. Дөрес, моның өчен еллар кирәк. Ләмнәрне яңа технология буенча эшкәртеп, киптерәчәкләр. Аннары шул урында агачлар утыртачаклар.

«Халык контроле» аша бер елга 1673 мөрәҗәгать кабул ителгән. Аларның яртысыннан күбе чүплекләр белән бәйле. Министр әйтүенчә, быел тиешсез урында барлыкка килгән чүплекләр буенча 4465 күрсәтмә төзелгән. 22 җинаять эше ачылып, 84 миллион сум штраф салынган.

– Балтач районында урнашкан «Арча» оешмасы Шушма елгасын пычраткан. Килгән зыянның күләме 6,1 миллион сумны тәшкил итә, – диде министр. – Ә халыкның табигатькә булган мөнәсәбәте көннән-көн яхшыра. Хәтта бер кеше дә тирә-яктагы хәлне үзгәртергә сәләтле. Мисал өчен, Саба районында яшәүче Билаловлар гаиләсе үз авылларындагы чишмәләрне төзекләндерә башлаган. Билаловларга башка авылдашлары да кушыла. Менә мондый күренешләр сөендерә.

Александр Шадриков зур шәһәрләрдә автотранспортның һаваны пычрату проблемасына да тукталды. Казан һәм Түбән Камада һавадагы азот диоксидының күләме 65 процентны тәшкил итә икән. Министр машиналарны газга күчерү проблеманы хәл итәргә булышачак дигән фикердә. Узган ел 2 мең техника газ белән йөри башлагач, һаваны пычратучы матдәләр 3,7 тоннага кимегән. Водородта хәрәкәт итүче транспортлар да табигатьне сакларга ярдәм итәчәк дип фаразлыйлар.

– КамАЗ оешмасы 2018 елдан бирле 700 электробус эшләп чыгарды. Тиздән алар республика шәһәрләрендә йөри башлар дип ышанабыз, – диде министр.

Утырышта Саба районында чишмәләр тарихын барлап, аларны төзекләндерү эшен башлаган Ләйсән Билалова да бар иде.

– Районыбыз экологы мәдәният йорты һәм китапханәләр системасына чишмәләрне барлау проектын тәкъдим итте. Бу – безнең уртак эшебез. Узган ел чишмәләр саекты, күп җирдә корыды. Шунлыктан без бер ел эчендә 22 авылда булып, андагы чишмәләрне барлап чыктык. Киләчәктә дә әлеге эшебезне дәвам итәргә уйлыйбыз, – ди Ләйсән ханым.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин табигатькә сакчыл карарга чакырды:

– Киләчәктә экологик вазгыять ничек булыр? Балалар, оныкларны нәрсә көтә? Без үзебезгә бирелгән байлыкны саклап тотарга тиеш, – диде ул.

Узган ел «Бердәм Россия» партиясенә 5500 наказ килгән. Алар арасында чүплекләр, чиста су хакында сораулар да шактый. Шуңа да Фәрит Мөхәммәтшин киләчәктә министрлыкка бу өлкәдә тагын да нәтиҗәлерәк эшләргә кушты. Ул Яңа ел бәйрәмендә Санкт-Петербургның чүпкә батуын искә алды. Бездә дә чүп күп, юл читенә чүп ташлаучылар да шактый, дип күрсенде Дәүсовет Рәисе.

Ул экологларга мөрәҗәгать белән дә чыкты. «Март аенда калдыклар белән эшләү мәсьәләсенә багышланган утырыш булачак. Сездән көнкүреш калдыкларын урнаштыру буенча тәкъдимнәр көтәм», – диде ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Кесәдә акча булу рәхәт

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Алсу Исмәгыйлеваның кызы Әминә дә үзенә шөгыль тапкан. Колаклы башлыклар (балаклава) бәйләп сата. Аңа – 15 яшь. Заказларны күбрәк дус кызларыннан ала икән. Заманча башлыкны бәйләргә интернеттан өйрәнгән. Бер башлык бәясе – 1700 сум. Җепкә 500 сумлап акча китсә, калганы Әминәнең үзенә була.

Идел буе мәшгульлек үзәгенә шалтыратып, студентларны укыган вакытта эшкә урнаштыру мәсьәләсе турында сораштык.

– Уку йортларының көндезге бүлегендә белем алучы бер генә үсмернең дә укыган вакытта эш сорап килгәне юк. Гадәттә, июнь башында мөрәҗәгать итә башлыйлар. Без эшкә махсус программа буенча урнаштырабыз, быелга финанслар юк әле. Предприятиеләр үсмерләрне эшкә алырга атлыгып тормый, ни өчен дигәндә, хезмәт иминлеге дигән нәрсә бар. Кемнең чит бала өчен җавап бирәсе килсен ди? Үсмерләрне эшле итү авыр. Мәктәпләр белән килешүләр төзесәк, хезмәт отрядларында азмы-күпме акча эшләрләр иде ичмаса. Тик бер мәктәп тә риза түгел. Мәгариф идарәләре дә кызыксынмый. Әгәр мәшгульлек үзәкләре белән килешү төзесәләр, хокук органнары тикшерә башлый. Хәзерге вакытта уку йортларын тәмамлаган 4 студент чиратта тора. Нәрсә тәкъдим итсәң дә, каршы киләләр. Бу – бик үзенчәлекле төркем, – диделәр үзәктә.

Сәрия МИФТАХОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Ютазы муниципаль районының социаль-икътисади һәм мәдәни үсешенә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы **Шәфигуллин** Аяз Әдип улы, республикада кулланучылар кооперациясе системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Кама» кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе **Бариев** Раил Габделнәгыйм улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Казан шәһәренең «Ышаныч» балалар һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет яшьләр сәясәте учреждениесенең «Сердәш» балалар һәм яшьләргә телефон аша психологик-педагогик ярдәм күрсәтү бүлекчәсе җитәкчесе **Сабирова** Наталья Анатольевнага **«Татарстан Республикасының атказанган яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

САНЛЫ ЕЛНЫҢ САНАУЛЫ ЭШЛӘРЕ

Яңалык

Сырхауларны электрон беләзек аша дәвалыйлар, яңа «акыллы шәһәр» төзиләр. Ерак тоелган киләчәк түгел, бүгенгебез инде бу. Мәгълүм булганча, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов 2022 елны Цифрлаштыру елы дип игълан итте. Үзгәреш җиле кайсы тармакларга кагылыр?

Интернетсыз интекмәсләр

Соңгы ике елда Татарстан күләмендә югары тизлектәге интернетка тоташкан социаль әһәмияткә ия оешмалар саны бермә-бер арткан. 2021 елда аеруча тырыштылар һәм 2296 объектны интернетлы иткәннәр иде. Гомумән, 3527 оешма – авыл китапханәләре, фельдшер-акушерлык пунктлары һәм башка биналарның интернеты бар. Быел да бу юнәлештә эш дәвам итәчәк.

– Шәһәрдә яшәүчеләр буларак, кайбер очракларны исәпкә алмаганда, без интернетсыз интекмибез. Шуңа да игътибарны авыл территорияләренә юнәлтәчәкбез. Цифрлы тигезсезлекне юк итәргә кирәк, – ди Татарстанның дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин.

Сүз уңаеннан, башкарылган эшләрнең зур күләме «Цифрлы икътисад» илкүләм проекты кысасында тормышка ашырылган. Әйтик, республиканың 305 авылы интернетлы булган. Министр сүзләренчә, быел халкы 100–300 кешене тәшкил иткән 60лап саланы интернетка тоташтыру нияте бар. Хәзерге вакытта Татарстанның 624ләп авылында һаман да 4G элемтәсе юк икән.

«Таттелеком» компаниясе белән гамәлгә ашырыла торган тагын бер программа нигезендә 100 меңләп йорт хуҗалыгын оптик чыбык аша интернетлы итәчәкләр. Былтыр бу программа кысасында 50 меңләп йортка бәхет елмайган.

Сырхауларга – электрон беләзек

Сәламәтлек саклау тармагын чын мәгънәсендә цифрлы алгарыш көтә. Министр әйтүенчә, Республика клиник хастаханәсендә электрон медицина картасы һәм сырхаулар өчен махсус беләзекләр барлыкка киләчәк. Димәк, хастаханә HIMMS дигән халыкара стандартка туры килә торган юнәлештә эшләячәк. «Еш кына табиб сырхауга билгеләнгән барлык дәвалану процедураларын контрольдә тота алмый. Бу яңалык нәрсә бирәчәк? Сырхауга электрон беләзек кидерәчәкләр, анда махсус цифрлы код булачак. Шушы беләзектә барлык анализлар, эш-гамәлләр теркәлеп барачак. Электрон медицина картасы пәйда булачак. Анда сырхау турында мәгълүматлар урын алачак. Кыскасы, дәвалау эше ачык булачак», – дип аңлатты Айрат Хәйруллин. Бу тәҗрибәне соңрак республиканың башка клиникаларында да кулланырга җыеналар.

Мәктәпкә дә кирәк!

Цифрлаштыру мәгариф системасында да бик кирәк. 2022–2023 елларда 1 млрд сум акчаны мәктәпләрне Wi-Fi белән тәэмин итүгә тотачаклар. Кайчандыр укытучыларның эшен җиңеләйтү өчен бирелгән ноутбуклар да искергән, аларны яңарту да күздә тотыла.

– «Ак Барс Банк» 24 меңләп ноутбук сатып алып бирәчәк. Республикада барлыгы 36 меңләп укытучы исәпләнә. Ноутбукны банк клиенты булганнарга бирәчәкләр. Башка зур компанияләрне дә әлеге акциядә катнашырга чакырам, – диде Айрат Хәйруллин.

«Я – школьник» дигән мобиль кушымтаны да камилләштерергә җыеналар. Исегездә булса, ул мәктәп укучыларының өй эшләре, билгеләрен күрсәтү, укытучы белән һәрдаим элемтәдә булу өчен барлыкка килгән иде. Хәзер кушымта балалар өчен психологик ярдәм һәм волонтерлык хәрәкәтләре турында хәбәр итеп торучы да булмагае. Аның ярдәмендә өстәмә белем алу мөмкинлеге дә туар.

Студентлар өчен яңалыкларга килгәндә, республиканың 5 югары уку йортында цифрлы кафедра ачылачак. Аны кайбер белем бирү йортларындагы хәрби кафедра белән дә чагыштырырга мөмкин. «Студентларга, дипломнарына өстәмә итеп, цифрлы

tatarstan.ru

һөнәр иясе булу мөмкинлеге дә биреләчәк», – диде Айрат Хәйруллин.

Бер ай көтәсе түгел

Үзгәреш җиле дәүләт хезмәтләренә дә кагылачак. Айрат Хәйруллин искә төшергәнчә, Татарстан дәүләт хезмәтләрен цифрлаштыру буенча Россия Президенты Указын вакытыннан алда үтәде. Алда торган бурыч – тагын 254 хезмәтне электрон төргә күчерү. «Цифрлаштыру гына түгел, хезмәт күрсәтү вакытын да кыскартасы иде, – диде министр. – «Әлбәттә, барлык хезмәтләр өчен дә бер үк вакытта булмас ул. Әмма аларның күпчелеген 1, 3, 14 көн дәвамында тормышка ашырырлык итәсе иде».

IT-паркка гына сыймыйлар

«Спартак» аяк киеме фабрикасы урынында яңа IT-квартал төзеләчәк. Бу елның декабрендә үк аны куллнышка тапшырып, Цифрлаштыру елының нәтиҗәләрен дә шунда әйтергә җыеналар.

– Бу мәгълүмати технологияләр юнәлешендә эшләүче компанияләр өчен мәйданчык кына түгел. Ул Казан эчендәге «акыллы шәһәр» булачак, – дип ышана Айрат Хәйруллин.

IT-квартал эш урыннары да бирер (3 меңләп), республика бюджетына саллы гына акча да (фаразлар буенча, 0,6 млрд) китерер дип өметләнәләр.

100дән артык чара

Айрат Хәйруллин әйтүенчә, цифрлаштыру юнәлешендә Татарстан Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан гына калыша. Моңа карап кына сан артыннан куарга җыенмыйлар.

– Рейтинг дип түгел, халыкның тормыш рәвешен җиңеләйтү, дәүләт хезмәтләреннән файдалану уңайлы булсын дип эшлибез, – диде бу җәһәттән министр.

Цифрлаштыру елы уңаеннан республикада 130 чара оештырылачак. Алар Казанда гына түгел, районнарда да узачак. Чаралар арасында ел дәвамында даими рәвештә уза торганнары да, аерым яшь категорияләренә караганнары да бар. Цифрлаштыруга бәйле фестиваль, форум (мәсәлән, «Kazan Digital Week»), конкурс («АлгаРитм»), дәрес, остаханәләр оештырылачак. Цифрлаштыру елына бәйле чараларны оештыру өчен 4 млрд сум күләмендә акча тотылачак.

– Ел уңышлы узды дип әйтер өчен, бердән, IT-кварталны тапшырырга, икенчедән, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электронлаштырырга, өченчедән, барлык торак пунктларны интернетлы итәргә кирәк, – диде министр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

«КЕШЕНЕ ЯРАТМАУЧЫ ҖИТӘКЧЕЛЕККӘ КИЛЕРГӘ ТИЕШ ТҮГЕЛ»

Беренче Президент

Бу сүзләрне Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиевтән ишеткән идем. Кайда нәрсә уңаеннан әйткәнен хәтерләмим, әмма бу фикер күңелнең түренә үк кереп оялады. Гомер буе җитәкче урында утырган кеше шулай дип әйткән икән, димәк, ул үзен дә күз алдында тоткандыр.

Минтимер аганың юбилее алдыннан Татарстанның халык шагыйре, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Разил Вәлиев белән очрашкач, сүзне әнә шуннан башладык. Нәкъ менә Разил туган белән очрашу очраклы хәл түгел. Зур-зур дәрәҗәләргә ирешеп тә, ул да гади татар егете булып кала бирә.

Бер кызыклы хәл. 4 гыйнварда Минтимер ага шалтырата моңа.

«Разил, чаңгы киемнәремне киеп чыгарга гына тора идем, синең турыда тапшыру барганын күрдем дә, киемнәремне салып, телевизор каршына утырдым. Тапшыруны ахырга хәтле карадым. Бер артык сүз юк, барысы да дөрес. Туган көнең белән сине!» – дигән.

– Озакламый сезнең дә туган көн, юбилей, Минтимер ага… – ди Разил.

– Шулай шул. Гыйнварда туу – бик җаваплы нәрсә ул. Табигатьнең иң кырыс вакыты бит. Салкын, кырыс айда туган кеше чыныкканрак, түземлерәк була кебек…

Тагын нәрсә турында сөйләшкәннәрен сорап тормадым, сүз куертыр өчен безгә шунысы да җитә иде. Кайбер җитәкчеләр, югары кәнәфигә менеп утырып бераз вакыт узуга, гади генә әйткәндә, «әлләкем» булалар.

Ә Минтимер ага Татарстанда гына түгел, илдә, дөньяда танылып, ничек кече күңелле булып кала ала икән?! Чаңгыда йөреп кайтырга дип чыгып барган җиреннән кире борылып, телевизор каршына барып утырган бит.

Үзе бер хикмәт инде. Кеше яратмаучыларны җитәкчелеккә якын җибәрмәү турында сүз чыккач, Разил болайрак сөйләде. Мәсәлән, кеше, аерым алганда иҗат кешесе, ни язса да, үзе турында яза яисә башкаларны үз күңеле аша үткәреп тасвирлый. Чөнки теләсә кем өчен бу дөньяда иң өйрәнелгән, иң яхшы белгән кешесе – ул үзе. Минтимер ага да кем турында сөйләсә дә (бу очракта җитәкчеләр була инде), иң элек үзен күз алдында тотадыр. Кеше яратмаучы ил агасы була алмый һәм тиеш тә түгел.

Разил Минтимер ага турында шактый күп белә, тормыш юлын махсус өйрәнгән. Иң кызыгы: Минтимер ага да Разил турында шактый белә икән. Күптән түгел очрашкач: «Син дә председатель малае түгелме соң әле?» – дигән.

«Әйе. Әти башта агроном, аннан председатель булган. Мине дә председательлеккә укытмакчы иде», – ди икән Разил. Минтимер ага: «Ярый әле ул юлдан китмәгәнсең», – дип куйган. Минтимер ага үзе дә – председатель малае бит!

«Ярый әле үзе дә ул юлдан китмәгән», – дип көлешеп куйдык. Разил Минтимер аганың татарча төзек җөмләләр белән сөйли белүенә һаман да шакката:

– 1970 нче еллар иде. Минем «Ялкын» журналында эшләгән чак. Минтимер ага хәзерге Фәннәр академиясе бинасында журналистларны җыйды. Һәм татарча чыгыш ясады. Бу зур вакыйга кебек истә калмас та иде, әмма татар теле эт типкесендә йөргән заман бит бу. Кая анда зур җыеннарда – хәтта кибетләрдә, җәмәгать транспортында да татарча сөйләү сәер тоела иде. Ә монда мелиорация министры менә дигән итеп, чын ихластан татарча чыгыш ясый. Шуның өстенә сөйләм теле бик образлы аның. Җитәкчелеккә китмәсә, Минтимер агадан, бәлки, менә дигән язучы чыгар иде.

«Ярый әле язучы булмаган, нинди җитәкчедән колак каккан булыр идек», – дип тагын кыстырып куям. Ә Разил: «Туфан аганың гел әйтә торган сүзе бар иде. «Иҗат кешесе өчен талантган кала иң кирәклесе – ихласлык», – ди торган иде. Минем фикеремчә, ихласлык – җитәкче кеше өчен дә иң кирәкле сыйфат. Әгәр синдә шушы сыйфат юк икән, нинди матур сүзләр сөйләмә, акыллы фикерләр әйтмә – халык сиңа ышанмаячак, әйткәннәреңне кабул итмәячәк», – ди.

– Аннары, Минтимер ага кешене тыңлый да белә ул.

– Монысы да шул ихласлыкка бәйле. Кайчак аның янына ярты сәгатькә дип кенә керәсең, сәгатьтән артык, икешәр сәгать буе сөйләшеп утырасың. Без инде кәгазьгә карамыйча да матур сөйләргә өйрәнеп беттек, әмма тыңлый белүебезне югалттык. Игътибар иткәнең бардыр, җыелышларда кайберәүләр чыгыш ясый, ә аннан соң чыга да китә. Димәк, башка кеше фикере аңа кызык түгел. Ә Минтимер ага кеше сүзенә бик игътибарлы. Аның белән киңәш-табыш итү – минем өчен бик зур шатлык, мәртәбә. Бер елны олуг галимебез Миркасыйм Госманов белән «Шәхесләр» сериясеннән китаплар чыгара башларга уйладык. Шуннан Миркасыйм ага: «Разил, эш башлар алдыннан Минтимер Шәриповичның фатихасын алып чыксак, әйбәтрәк булыр иде», – диде. Кердек, максатны аңлаттык, шәхесләрнең исемлеген дә күрсәттек. Минтимер ага шунда ук үз фикерен әйтте: «Бик игелекле эшкә тотынгансыз, шәхесләр – һәр милләтне тотып торучы алтын баганалар ул», – диде. Күңелгә канат та куйды, китап чыгару өчен ярдәм дә оештырды. Аның янына һаман кергәләп, киңәшләр ала тордык. Берсендә: «Татарның Яруллиннары бар бит әле. Бер гаиләдән өч музыкант, композитор тагын кайсы халыкта бар?» – диде. Ул Заһидулла, Фәрит, Мирсәет Яруллиннарны күз алдында тота иде. Мәҗит Гафури турында да әйтеп куйды. «Аны төрле якка тарткалыйлар, ул бит – чын татар әдибе. Шуны аңлатып язарга иде», – диде. Муса Җәлилне дә телгә алды. «Кайсы халыкта шундый шәхес бар? Җәлил турында өстәмә мәгълүматлар да юк түгелдер», – дигән иде. Без яңа гына Муса Җәлил турында китап чыгардык. Аңа 500дән артык документ кергән, шуның яртысыннан артыгы моңарчы бер кайда да басылмаган. «Шәхесләр» сериясенең асылы да шул бит – моңа кадәр дөнья күрмәгән яки, цензура аша узып, шактый кыскартылган документларны эзләп табып, шәхесләребезнең моңарчы билгеле булмаган сыйфатларын ачу. Бүгенгә 80нән артык китап чыкты инде, озакламый Яруллиннарга, Мәҗит Гафурига, Нәкый Исәнбәткә багышланганнары да дөнья күрәчәк.

Разил Вәлиевнең шәхси архивыннан

– Разил туган, сине тыңлап утырам да, Президентның мәшәкатьләре болай да хәттин ашкан була, ничек барысына да өлгерә икән ул, дип тә уйлап куям.

– Әле бит Минтимер ага дөньяның иң буталган вакытында Президент булды. Мин аның сәясәттә дөньякүләм дәрәҗәдә фикер йөртә алуына шаккатам. Бер уйлаганда чепчи татар авылында туган, гади татар мәктәбендә белем алган һәм сәясәттә дөнья сәхнәсенә чыга алган шәхес бит ул. Бүген: «Татарча укып, кая барып була?» – дип сөйләнүчеләргә мин Минтимер аганы мисал итеп китерәм.

Минтимер аганың акылы, зирәклеге турында күп уйлыйм мин. Берзаман, президентлыктан киткәч инде бу, аның кабинетына кердем. Өстәлдә, урындыкларда – бөтен җирдә китап. «Шул хәтле китапны укып чыкмакчы буласызмы?» – дим. «Барысын да укып чыгу мөмкин түгел инде ул. Президент чагында вакыт бик тимәде, хәзер күбрәк укырга иде исәп. Гөнаһ булса да әйтим инде, мин үземне шактый мәгълүматлы кешегә санап йөри идем, бераз ялгышканмын икән. Китап укымау – һәр җитәкченең зур ялгышы ул. Чөнки бөтен кеше синең авызыңа карап, һәр сүзеңә: «Әйе, әйе», – дип торганда, үзеңне иң акыллыга саный башлавың да мөмкин бит…» – дигән иде ул. Минтимер ага үзен барысына да баш, барысына да түш, дип санамады.

– Бер кызык әйбер сөйлимме?

– Сөйләп кара!

– Заманында аңа туган тиешле Ринат Фәрдиевне, урыны оҗмахта булсын инде, Зәй районына хакимият башлыгы итеп куйганнар иде. Командировка вакытында шуның янына кердем. «Ринат Шәехович, абыегыз Президент булгач, күп мәсьәләләрне җиңел генә хәл итә аласыздыр инде?» – дидем. Сорау, әлбәттә, тупасрак, уңайсызрак иде. Әмма ул үпкәләмәде һәм үзе бер гыйбрәтле вакыйганы сөйләп алды. Чыннан да, Президент янына кергән булган ул. Авыл хуҗалыгында техника җитмәвеннән зарланып алган: «Бер-ике комбайн бирә алмассыз микән?» – дигән. Минтимер ага башта өстәл тартмасын тартып чыгара, нидер эзли. Үзе: «Тәк, монда юк икән…» – дип сөйләнә. Ринат Шәехович исә, комбайн алыр өчен берәр документ бланкын эзлидер дип өметләнеп утыра. Шуннан соң Минтимер ага кием шкафын, башка шкафларны ачып карый: «Монда да күренми», – дип сөйләнә. Шуннан Ринат Шәеховичка борыла да: «Энем, комбайн бер җирдә дә юк икән бит!» – дип куя. «Шуннан җир тишегенә кереп китәрдәй булдым, Минтимер абыйдан бүтән берни дә сорамадым», – дигән иде.

– Риман туган, Минтимер ага президентлыктан китеп, Дәүләт киңәшчесе булгач та үз агымында калды. «Президент эшенә катнашмаячакмын», – дип сүз дә биргән иде. Бу да – олпатлык һәм ихласлык билгесе, мондый шәхесне берниндм кәнәфи дә үзгәртә алмавына бер дәлил. Аңа озын гомер телим.

Теләкләребез дә Минтимер аганың үзе кебек ихлас.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

ТАРИХ ДӘШМИ КАЛГАННЫ ЯРАТМЫЙ

«Түгәрәк өстәл»

Тарихи роман кайчан фентезига әйләнә? Ни өчен бездә тарихи геройлар һәм сюжетлар кытлыгы? Әлеге кытлыктан ничек котылырга һәм әдәби әсәрдә тарихи төгәллекне ничек сакларга? Татарстан Язучылар берлегендә тарихчылар белән язучылар әнә шул хакта фикер алышты.

Берлек рәисе Ркаил Зәйдулла әйтүенчә, язучы, тарихи әсәргә алына икән, тарихчыга мөрәҗәгать итми хәле юк:

– Әдәбият тарих белән турыдан-туры бәйләнгән. Шуңа күрә безнең «түгәрәк өстәл» тирәсенә җыелу бик табигый. Бу очрашуларны даими итәргә уйлыйбыз. Безнең мәсләгебез бер.

Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Алтын Урданы тикшерү үзәге җитәкчесе Илнур Миргалиев исә язучылардан тарихи сюжетларга күбрәк мөрәҗәгать итүләрен үтенде:

– Тарихчылар зур эш алып баралар. Бу – туган якны өйрәнү дә, гомуми тарих та һәм башка өлкәләр дә. Татар тарихының җиде томлыгы әзерләнде. Ул, әлбәттә, академик тел белән язылган, ләкин әле русларның да академик басма тәкъдим иткәне юк. Безнең татар тарихы бик саллы. Тарихчыларның хезмәтләре башлыча «татаровед.рф» сайтында дөнья күрә. Без эшләргә тырышабыз инде, ләкин аны киң катлауга җиткерүдә мөмкинлекләре чикле. Халыкка тарихны җиткерү өчен, безгә язучыларның ярдәме кирәк. Шуңа күрә без әлеге очрашуны оештыруны сораган идек. Чөнки әдәбиятта тарихи сюжетлар бик ачылып бетми. Татар тарихы искиткеч бай, аның батырлары да җитәрлек. Әгәр инде сез бу темага алынасыз икән, бигрәк тә тарихи хрониканы торгызганда ярдәм итә алыр идек. Әлбәттә, язучы әсәр иҗат иткәндә фантазияне дә куллана, әмма эченә сюжетларны да кертеп җибәрсә, яхшы булыр иде. Тарихны академик басмалар белән генә популярлаштырып булмый. Шуңа күрә безгә язучылар белән күбрәк эшләргә кирәк. Без язмаларны бирергә әзербез. Аннан соң без бөтен сюжетны күрмәскә дә мөмкинбез, язучы үтә сизгер, ул без күрмәгәнне дә күреп алырга мөмкин.

Галим теләге булган һәммә кешенең тарихи этногенезда казынуы, милләт булып формалашуыбызны төрлечә боргаларга маташулары хакында да кисәтте. Мәгълүм булганча, җанисәп вакытында бу эшләр бигрәк актив алып барылды. «Мин Казанда бу теманы тирәнтен белгән 4–5 этнологны гына беләм. Тарихчылар фикер белдерергә мөмкин. Ә менә дилетантлар җитәрлек. Алар тарихтан төрле социаль катлауларны йолкып чыгаралар да нииндидер фикер әйтергә маташалар», – ди Миргалиев. Галим бу җәһәттән Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтләрен дә телгә алды һәм аңламаган кешеләрнең милләт белән сословиеләрне бутаулары хакында шактый мисаллар китерде. Сүзен йомгаклап, ул боларның барысын да аңлаешлы тел белән халыкка җиткерергә кирәклеген ассызыклады.

Ни өчен халыкны тарихка якынайтырга кирәк? Тарихчы Дамир Исхаков фикеренчә, милли үзаңны шулай гына үстереп була. Әмма тарихи роман үзе дә хәйран гына проблемаларга тарый:

vk.com/pechenbazar

– Минем күзәтүләр буенча, тарихи романнар үзләре дә тикшерүгә мохтаҗ. Мәсәлән, әлеге юнәлештә эшләгән язучыларга багышланган ничә диссертация бар? Шәхсән минем андый фәнни эшкә юлыкканым юк. Бер-ике кешегә әйтеп карадым, ләкин алар ахырына кадәр җиткерә алмадылар. Безнең тарихи романнарга анализ ясаганыбыз да юк. Шуңа күрә нәрсә дөрес анда, нәрсә ялган, кайсы яхшы, кайсы начар – без, чынлыкта, белмибез. Тәнкыйть итүем түгел, күзәтүләремнән чыгып әйтәм: бик күп язучыларга тарихи белем җитми. Үткәннәрдә кылдан нечкә күренешләр бар, аны тирәнтен аңламаганда, башка юнәлешкә кереп китеп, тарихи романны фентезига әйләндерергә мөмкин. Фентези жанры да бар, әлбәттә, ләкин безгә тарихи җирлекне белү мәсьәләсе әһәмиятлерәк. Ул яктан бездә шәхесләр турында язылган әсәрләр дә җитәрлек түгел. Мәсәлән, Йосыф Акчура, Садри Максудиларны гына алсак та, алар хакында Төркиядә берничә фәнни китап чыккан була, бездә бернәрсә дә юк. Кемдер эшли, без эшләмибез. Бусы – күбрәк тарихчылар колагына. Икенчесе. Мин соңгы вакытта татар дастаннары белән шөгыльләндем. Татар дастаннарында тарих сакланган да инде. Аларны укып кына да роман язып була. Әдәбиятта тарихчылык мәсьәләсенә килгәндә, галимнәр белән консультацияләр бик кирәк. Икенчедән, тарихи әсәрләрне уку кирәк. Нечкә әйберләр турында язган вакытта, ныграк фикер алышуларсыз да булмый. Әйтик, Ринат Мөхәммәдиев Мирсәет Солтангалиев турында язды, бу чор турында документаль база бик зур. Ләкин Ринат күрмәгән яклар да бар. Шуңа күрә, бәлки Тарих институты белән бергә аерым очрашулар да үткәрергәдер. Чөнки тарихи әсәрләр тарихи аңны формалаштыру өчен кирәк. Барыбыз да беләбез: халыкның милли аңы түбән. Романнар нигезендә аны күтәрергә була.

Бездә тарихи романнар кытлыгы булганда, актив эшләүчеләр һәм 1552 ел фаҗигасен гражданнар сугышы итеп тасвирларга омтылучылар да бар. Бу хакта Ркаил Зәйдулла менә нәрсә ди:

– Казан ханлыгының алыну сәбәбен эчке тарткалашуга, гражданнар сугышына кайтарып калдырмакчы булучылар да бар. Күптән түгел шундый әдәби әсәр укыдым. Анда, имеш, Казан ханлыгын алырга урысларга караганда күбрәк татарлар килгән, Шаһгалинең 60 меңлек гаскәре булган дип язылган. Касыйм ханлыгының үзендә дә 4–5 мең сугышчыдан артык булмаган югыйсә. Шаһгалинең 500 кешелек гаскәр белән килүе турында чыганаклар да бар.

Тарихчылар мәгълүмат белән булышабыз дип әйтсәләр дә, чынлыкта, язучыга бик күп нәрсәне үзенә уйлап табарга кирәк була. Тик монда бик сак булырга, артык фантазиягә бирелергә ярамый. Бу хакта язучы Батулла болай кисәтте:

– Тарихта документка кадәрге әйберне син уйлап табарга тиеш. Образның логикасыннан чыгып, тарихын белергә тиеш. Чөнки бездә документлар сакланмаган. Бәетләр, җырлардан кала… Бәет дигәннән, ни өчен халык, Сөембикәнең Мәскәүгә озатылганын белә торып, улы Үтәмеш белән бергә манарадан ташланган дип бәет чыгара? Әдәби уйдырма дисәк тә, бәет тарихка якын. Халыкның ханбикәсен әсирлеккә бирәсе килми, шуңа күрә бәеттә аны манарадан ташландырып һәлак итә.

Әлбәттә, халык китаптан ерагайган заманда, кино бик зур ярдәм итә алыр иде. Якутиядә шулай да ул. Ә бездә бу җәһәттән хәлләр катлаулырак. Россия Кинематографистлар берлегенең Татарстан бүлеге рәисе Илдар Ягъфәров шулай ди:

– Режиссерлар татарның катлаулы үткәненә багышланган, әйтик, Россиядә көчләп чукындыру турында фильм төшерерләр дә иде. Әмма бу бик катлаулы. Бигрәк тә бүген. Без, Мәдәният министрлыгына барып, шундый картинага акча сорасак, идеология ягыннан бу картинада проблемалар бар, дип җавап бирәчәкләр. Без хәзер, идеология проблемаларыннан читләшер өчен, автор картиналарын төшерәбез. Татар тарихы турында яңа әсәрләр, кызганыч, юк. Ярый әле Рамил Төхвәтуллин үз вакытында «Зөләйха» фильмын төшерде. Мин ул юлыккан авырлыкларны да бик яхшы беләм.

«Бүген андый картина төшереп булмас иде», – дип сүзгә кушылды Дәүләт Советы депутаты, халык артисты Рамил Төхвәтуллин да. Ул татарның символларына игътибарлы булырга чакырды. Аның әйтүенчә, алар да – бүген басым астында.

Фикер үзеннән-үзе Үзбәкстан хакимиятенең Самара өлкәсе Кондырча җирлегендә Аксак Тимергә һәйкәл куярга теләк белдерүенә барып тоташты. Һәйкәл куюга конкурс турында Үзбәкстан Министрлар Кабинеты карары чыккан. Проект 2024 елга Россия Тышкы эшләр министрлыгы һәм Мәдәният министрлыгы белән берлектә тормышка ашырылырга тиеш. Татарларның әби-бабалары яшәгән канкойгыч сугыш урынында йөз меңнән артык кешене суеп үтергән әмиргә һәйкәл куюга каршы чыгу табигый. Казахстан тарихчылары да, Мәскәү галимнәре дә әлеге һәйкәл куелуга каршы чыккан инде. Бу хакта тарихи семинарларның берсендә профессор Вадим Трепавлов белдергән иде. Татарстан Язучылары да, әлеге һәйкәлгә каршы чыгуларын белдереп, мөрәҗәгать әзерли. Тарих дәшми калуны яратмый.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

ПОПОВ АЛЕКСЕЙ ГАВРИЛОВИЧ

(14.12.1934 – 17.01.2022)

«Газпром трансгаз Казан» чикләнгән җаваплылыктагы җәмгыяте ветераны Алексей Гаврилович Попов 17 гыйнвар көнне 88 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте. Җәмгыять коллективы, Алексей Поповның элекке коллегалары өчен дә зур югалту бу.

Ул, сайлап алган һөнәренә тугры калып, бөтен гомерен газ сәнәгатенә багышлады.

Алексей Гаврилович 1934 елның 14 декабрендә Тамбов өлкәсендә дөньяга килә. 1958 елда Уфа дәүләт нефть институтында «Нефть һәм газ чыганакларыннан файдалану» белгечлеген алып чыкканнан соң, «Әлмәтнефть»тә нефть һәм газ чыгару операторы булып эшли башлый. Барлык карьера баскычларын узып, үз эшенең остасына әйләнә: республиканың нефть-газ тармагы объектларында газ чыгару мастеры, компрессор станциясе мөдире, производство-техник бүлеге һәм газ цехының өлкән инженеры, район инженер-диспетчерлык хезмәте башлыгы вазыйфаларында хезмәт куя.

Алексей Гаврилович Попов 1975 елдан «Таттрансгаз»да җитәкче вазыйфаларын биләде, 2002–2012 елларда «Таттрансгаз» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (хәзер – «Газпром трансгаз Казан») генераль директорының җитештерү буенча урынбасары булып эшләде. Алексей Попов «Россия Федерациясенең атказанган нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре», «Россия Федерациясе ягулык-энергетика комплексының мактаулы хезмәткәре», «Газ сәнәгатенең мактаулы хезмәткәре», «Газ сәнәгатенең хезмәт ветераны», «ТАССРның атказанган нефтьчесе», «Татарстан Республикасының атказанган газчысы», «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте ветераны» дигән мактаулы исемнәргә лаек булды.

Ул киткәч, Җәмгыять бүгенге газчылар буыны белән үз белемнәрен, тормыш тәҗрибәсен уртаклашкан изге күңелле, мәрхәмәтле остазын югалтты.

Бу авыр көннәрдә Алексей Поповның гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклашабыз. Аның якты истәлеге безнең күңелләрдә – дуслары һәм коллегалары күңелендә озак сакланыр. Алексей Гаврилович Поповның исеме предприятие тарихына һәм безнең күңелләргә мәңгегә уелып калыр, ә ул калдырган традицияләр коллективның хезмәт казанышларында сакланыр.

«Таттрансгаз» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективы

Татарстан Республикасы Президенты киңәшчесе Кантюков Рәфкать Абделхәй улы, «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте ветераны, Россия Федерациясенең атказанган нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре

ПОПОВ Алексей Гавриловичның

вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Һөнәри осталыгы һәм үзенә тапшырылган эшкә гаять җаваплы каравы Алексей Гавриловичка коллегалары арасында зур абруй-хөрмәт китерде. Аның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Бәхет формуласы

Бер татар физигы зур ачыш ясаган. И, физигымы, химигымы инде шунда, математигымы. Татар химигы дию дә беркадәр ят булып тора әле. Берәрсе: «Карале, татарның химиклары да бармыни?» – дип сорар сыман. Гомумән, татарның химигы, физигы, математигы булу – сәер ишетелә. «Татар галиме» дигәндә дә без я тарихчыны, я тел, я әдәбият белгечен генә күз алдына китерәбез. Шулай күнегелгән. Ә болай, гади тормышта... татарда бары тик җырчылар гына бардыр кебек. Телевизор кабызасың – җырчы, радио ачасың – җырчы, интернетка керәсең – җырчы. Менә элек халыкның күп өлешен сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр һәм сугышчылар тәшкил иткән. Хәтта сәүдәгәр дигәне дә сугыш серләрен яхшы белгән. Һөнәрчесе дә шулай инде. Җыеп әйткәндә, аларның барысы да яугир, сугышчы булган. Хәзер барысы да җырчы. Шуңа күрә, яуга калкыныр чакларда да татар, мәйданга чыгып, берәр җыр җырларга тотына. Талантлы милләт.

Әнә шул талантлы милләтнең бер химигы зур ачыш ясаган. Бәхет формуласын тапкан бу. Үзеңне дә, башкаларны да бәхетле итү мөмкин, алай гына да түгел, бик гади һәм җиңел икән. Бары тик формуласын гына белергә кирәк. Менә шул формуланы татар галиме ачыклаган. Ну, бу: «Милләтебез бетә бит, нигә аны миннән башка беркем дә сакламый?» – дип төзек җөмләләр белән сөйләшә торган кеше түгел инде. Башка телдә укыган, башка мохиттә эшләгән, шулай да үзлеген югалтмаган. Безнең сыманрак инде. Ләкин галим. Физик. Яки математик. Яки химик. Ләкин татар.

Американың берәр кешесе шундый ачыш ясый алса, шундук Нобель премиясе даулый башлар иде. Аннан соң бәхетле булырга теләүчеләрдән күп төрле төркемнәр җыеп акча эшләр, видеоязмалар, китаплар чыгарыр, шул рәвешле миллионерга әйләнеп, танылган да, бай да булып яшәр иде. Яһүд булса, бу формуланы шундук яшерен гыйлемгә әйләндерер, аны бары тик бик бай һәм затлы милләттәшләре белән генә уртаклашыр, шул рәвешле тегеләргә бәхет сатып, үзе баеп калыр иде. Кем генә булса да, бу ачышны танылу һәм баю хакына кулланыр, аның файдасын күреп калырга тырышыр иде.

Ә татар галиме... аны социаль челтәргә элгән. Татар телендә. Белмим, ни өчен шулай эшләгәндер. Югыйсә татарчасы да әллә ни түгел инде. Бәлки, ул бу формула белән иң беренче чиратта милләттәшләрем танышсын, башта алар рәхәтен күрсен, ә мин баерга да, танылырга да өлгерермен дип уйлагандыр. Шулкадәр зур бүләк ясаганы өчен, бәлки, күңеленнән генә рәхмәт сүзе дә көткәндер әле. Бәяләрләр, кулланырлар, бәхетле булырлар дип өметләнгәндер. И-и-и, галим дип аталса да, шул авыл баласы бит инде, бәрәңге яфрагы кебек беркатлы җан иясе.

Социаль челтәр моны бөтенләй башка яссылыкта күрә. Менә күз алдына китерегез – бәхет формуласы бирелгән. Һәм шуның астында татарлар фикер алыша:

– Беренчедән, ник ул татарча дөрес яза белми?! Татарның галимнәре дә надан булгач, башкаларга ни сан?

– Татар телендә «хава» дигән сүз юк, ул «һава» дип языла.

– Хава, бәлки, «Ева» мәгънәсендәдер? Татарча Хава була түгелме?

– Юк, анысы да «Һава» була.

– «Һава» түгел, «Хәүва».

– «Һава» татар сүзе түгел, ул гарәптән кергән.

– Татарча ничек була?

– Татарда андый сүз юк.

– «Күк» була. Күк йөзе.

– Һава монда «воздух» мәгънәсендә. Һава сулау. Күк бармый.

– «Яңгырлар ява» дип язу дөрес түгел, «яңгырлар явалар» булырга тиеш.

– Әстәгъфирулла, моның һәр сүзе саен хата бит. Нинди галим бу, кайда эшли?

– Яхшы галим булса, базардадыр инде. Ит чабадыр. Булдыклылары шунда күчеп бетте бит, акчасы күп дип.

– Юк, бу фәлән вузда укыта.

– Шулайдыр шул. Анда бит наданнар гына калды. Бу да хәтта татарча да яза белми. Татарчасы шулай булгач, урычча бөтенләй бум-бум бит инде.

...Мин тагын да дәвам итеп тормыйм. Бу язмаларның сәбәпчесе – талантлы галимнең яңа ачышы, бәхет формуласы. Үзеңне дә, башкаларны да бәхетле итү мөмкин, әле алай гына да түгел, бик гади һәм җиңел икән. Бары тик формуласын гына белергә кирәк. Ә ул формула күз алдында иде.

Шулай хәреф хаталарын, галимнең шәхесен, белем дәрәҗәсен тикшереп, алар сүзнең нәрсә турында баруын аңламадылар. Бәхет формуласын күрә белмәделәр. Хәер, бу аларга кирәк тә түгел, болар башка кешенең хатасын, җитешсезлеген табып, аны булдыксызга чыгарырга тырышудан да бәхетле иделәр.

pixabay.com

УКЫЙ ТОРГАН ЕГЕТ БУ

Остаз

Арча педагогия көллиятенең легендар директоры Илдус СӘГЪДИЕВ Яңа елны 85 яшьлек юбилее белән каршы алды. Үзе әйтүенчә, бу көнне аның телефоны тынып тормаган, истәлекләргә бирелә-бирелә, күз яшьләренә ирек куеп, котлаулар кабул итеп утырган. Хәләл җефете – безгә химия фәненнән белем биргән укытучыбыз Флюра апа кыз-уллары, кияү-киленнәре, оныклары белән затлы итеп табын әзерләгән, шулай итеп бергә-бергә иң кадерле кешеләренә сый-хөрмәт күрсәткәннәр.

Котлаулар бер көнгә генә сыешмаган әле. Шулай булмый хәле дә юк. Педагогия училищесында 41 ел (шуның 21е – директор, 8е завуч булып) эшләү дәверендә Илдус абый кемгә генә белем бирмәгән дә кемне генә җылы сүз белән юатмаган. Газетада язмам чыккан саен, олы башын кече итеп, минем белән дә элемтәгә чыкмый калмый ул. Мактап та ала, тәнкыйтьли дә, үзенчә киңәшләрен дә бирә, әмма беркайчан да күңелне төшерми. Илдус абый сөйли башласа, мин йотлыгып тыңлыйм.

Балачак

– Биектау районындагы безнең Урал авылы 14 йортлы гына иде. Әтиебез Габдрахман сугышның беренче көннәрендә үк хәбәрсез югалды. Безне – 6 баланы әниебез Бибимәрзия җыеп-җыйнап үстерде. Укуга бик һәвәс булдык. Мәйданы 40 квадрат метр тирәсе булган агач йорт иртәнге якта колхоз идарәсе, сәгать 8дән соң мәктәп, кич белән клуб булып хезмәт итте. Без, 20ләп бала, барыбыз бергә укыйбыз. Ленин ордены белән бүләкләнгән Габдулла исемле укытучыбыз беребезне дә тик утыртмый. Кара тактада 2–3 укучы берьюлы нидер яза. Кечкенә генә китапханә дә бар. Китапларны чиратлашып укыйбыз. Аларның барысы да, Островский, Толстой китаплары да татарча иде.

Дәресләр тәмамланганнан соң йорт эшләре көтеп тора. Каз көтәбез, кич белән сыерны көтүдән каршы алырга барабыз. Ял көнне колхоз көтүенә чыгабыз. Төнгә бер эш – китап уку. Берәр җайлы почмакта лампаны яндырасың да, укыйсың да укыйсың. Безнең авылда китап укымаган бала юк иде. Мин күбрәк тә укып ташлаганмын, ахры. Кечкенәрәкләр, нинди китап укыдың, әйдә сөйлә әле, дип әйләндереп алалар да җибәрмиләр иде. Уралда башлангычны тәмамлагач, 8 чакрым ераклыктагы Ямаширмә мәктәбенә юл тоттык. Математика белән физиканы Әгъләм абый укытты. Мантыйкый фикер йөртүгә мәсьәләләр бирә иде ул безгә. Казан педучилищесына укырга керергә дә ул тәкъдим ясады.

Казан

Мәктәпне «5»кә генә тәмамлаганга, имтиханнарсыз гына алдылар. Әле ярый шулай булган. Югыйсә рус теленнән диктантны яза алмаган булыр идем. Иң беренчесен язгач, үз күзләремә ышанмадым: кып-кызыл, шыр хата. Булдыра алмыйсың дип, кайтарып җибәрергә дә исәпләре бар иде.

Директор Абдулхак абый Касыймов кына коткарып калды: математикадан укыта иде, ә мин ул фәнне яхшы беләм. Тырыша торгач, педучилищены «5»кә генә тәмамладым.

Армиядә өч ел хезмәт итеп кайткач, Казан педагогика институтына имтихан бирергә килдем. Билеттагы мәсьәләләрне бик тиз чиштем, әмма теоретик яктан аңлату кыен. Онытылган. Шулчак бүлмәгә булачак деканыбыз Бари Газизов килеп керде. Минем азапланганны карап торды да: «Әйдә, «5»ле куегыз, укый торган егет бу», – диде. Шулай итеп мин студент булдым. Тик матди хәлнең начар булуы гел сиздереп тора. Дәресләрдән соң вагон бушату, кайда нинди эш бар, шуңа ябышу туйдырды. Беренче курсны тәмамлагач, Дәрвишләр бистәсендәге оптика-механика заводына бардым да лаборант булып урнашырга сөйләшеп кайттым. Заводтан чакыру килгәч, декан янына кердем, хәлем җиңел түгел, читтән торып укырга күчәм, дидем. Ул мине җибәрмәде, шул көннән Ленин стипендиясе билгеләде. Үзем дә тырыштым инде. Төнгә кадәр тулай торакның уку залында утыра идем. Аспирантурада калырга да кыстадылар, әмма ул вакытта без Флюра апаң белән гаилә корып, бала көтә идек инде. Юллама белән Арчага юл тоттык.

Арча

Без педучилищега килгәндә, Мәгариф министрлыгы бу уку йортыннан әллә ни канәгать түгел иде кебек. Шулай хәтердә калган. Директорыбыз Мөнәвир Ибраһимов аңа яңа сулыш өрде: уку йортының матди-техник базасын ныгытты, янкорма салдырды, тулай торак, ашханә төзетте. Коллектив туплаганда да, иң элек үзебезнең педучилищеда укып, югары уку йортын тәмамлаган кешеләрне эзли, нинди сыйфатларга ия булуларын ачыклый иде. Ул 18 ел директор булып торган чорда Арча педучилищесы иң алдынгы урынга чыкты. Киләчәккә карап эш йөртә белде шул. Укучылар саны елдан-ел арта бара, ә бинаның мәйданы кечкенә. Мөнәвир Гәрәевич проект-смета документлары әзерләтте. Әмма аңа эшне башларга рөхсәт бирмәделәр. Үз урынына мине калдырганда, бинаны төзетергә наказ әйтеп калдырды. Шул проект турында сөйләшергә дип, райкомның беренче секретаре янына кердем. Миңа сезнең педучилищегыз бернәрсәгә дә кирәкми, дип борып чыгарды. Коллектив янына кайтырга бик озак кыенсынып йөрдем. Миннән берни килеп чыкмый икән дигән фикергә килдем дә, директорлыктан азат итегез дип, гариза яздым, Мәгариф министрлыгына юл тоттым. Министр урынында булмады. Урынбасары безнең училищены тәмамлаган кеше булып чыкты. Әйтмәгән сүзен калдырмады, сүгеп кайтарып җибәрде. Аның каравы, әллә нинди юлларын табып, яңа бина салырга ярдәм итә алды. Без аны хуҗалык ысулы белән салдык. Бу инде барлык укытучылар да төзелештә үзләре катнаша дигән сүз. Шулай булып чыкты да. Хәзер дә гаҗәпләнәм: ник бер кеше зарлансын, ник бер кеше сүз әйтсен шунда! Ярты көн укытабыз, яртысы эшләп үтә. Бер җаена төшенгәч, авыр булса да, тукталып калмадык: шул ук ысул белән укытучыларны фатирлы да иттек.

«Укытучы нинди булырга тиеш?» дигән сорауны еш бирәләр миңа. Аның җавабы кем өчен дә бер инде. Иң элек ул балаларны яратырга, аларны шәхескә тиңләп эш итәргә, үзендә булган белемне күңелләренә сеңдерергә тиеш. Әйткәнемчә, үзем дә, фәлән абыйда укымасам, бу һөнәрне сайламаган да булыр идем, диючеләр исемлегендә бит мин. Кызганыч, педучилищега килүчеләр арасында төрлесе бар. Кемдер ара якын булганга, я әти-әнисе кушканга, я кирәге чыгар әле дип, укып торырга килә. Әмма нинди генә һөнәр ияләре булсалар да, безне тормыш итәргә, яшәргә Арча педучилищесы өйрәтте, дип әйтерлек булсыннар безнең укучыларыбыз.

Гаилә

Флюра апаң белән өч бала үстердек. «Кайда йөрисең, ник өйдә эшләмисең?» – дип битәрли белмәде. Бер коллективта укыткач, берәрсен тәнкыйтьләсәң, үзеңнекен кара, дип әйтүләре дә бар иде. Тик мондый сүзләргә форсат булмады: Флюра һәр дәрескә ныклап әзерләнеп, бар күңелен биреп укытты. Хәзер инде балалар, оныклар, онычыклар белән әвәрә килеп яшәү – безнең өчен иң зур сөенеч.

... Минем Илдус абый белән Арча урамнарында йөргәнем бар. Юлда очраган һәр кеше аны таный, йөгереп килеп, хәлен сораша. Сездән дә бәхетле кеше юктыр, Илдус абый, дигән идем шулвакыт, сокланып. Илдус абыйны хәтта 80 яшендә укытырга да чакырганнар иде. БДИ белән мәшәкатьләнгән катлаулырак чор иде бу. Район ветераннар советын җитәкләгәндә, ул берничә ел өлкән кешеләрнең тормышын кайгыртып мәш килде. Арчалылар өчен генә түгел, төрле якка таралган меңләгән укучылары өчен дә ул – әле һаман да киңәшче, ярдәмче. «Ватаным Татарстан»ның да якын дусты ул. Арчада китап, газета һәм театр көннәре үткәргәндә, без Илдус абыйның бу районда «ВТ»ны күптән укый торган кеше икәнлеген дә ачыкладык. Кулыннан каләмен дә төшергәне юк. Берәр җирдә сабакташларымны очратсам яки шалтыратсалар, беренче булып: «Илдус абыйның хәлләре ничек икән?» – дип сорыйлар. Шөкер, хәлләре әйбәт укытучыбызның. Исән-сау булып, безне озак еллар шулай шатландырып торсын дигән теләктә калыйк.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

УЛЫМ, ТАРТМА ИНДЕ... СӨРМӘҢНЕ!

Битенә – кершән, иренәнә иннек сөрткән, күзенә сөрмә тарткан ир-атлар – хәзер инде җәмгыять өчен яңалык түгел. Килешсәк тә, килешеп бетә алмасак та, поп-мәдәниятнең үсеше, косметика брендларының сатып алучыларын ике мәртәбә арттырырга тырышуы, үз-үзеңне ничек телисең, шулай күрсәтү ирекә арту, «батырлык», «кыюлык» төшенчәләренең тарихи мәгънәсен югалтуы мондый «сылу»ларның саны артуга бары уңай йогынты ясаячак.

Әмәнә Кытай хакимияте моның белән килешергә һәм, бизәнеп, телевидениедә чыгыш ясаучы ир затларына тыныч кына карап утырырга җыенмый икән. Бу күренешне тыюлары турында Гонконгның «The South China Morning Post» газетасының рәсми сайтыннан укып белдек. Кытай хакимияте әлеге карарын бизәнгән артистлар образының ир-атлар турындагы традицион күзаллауга туры килмәве белән аңлата.

Әлбәттә, косметика һәм ир-атлар арасындагы мөнәсәбәтләр яңа гасырда гына барлыкка килмәгән. Борынгы Мисырдагы ир-атларның, бизәнеп, фиргавенгә охшарга тырышулары, феодалларның, бай булып күренер өчен, битләрен агартуы, кинематография һәм музыка сәнгате йогынтысы астында «мэйк-ап» индустриясенең үсү-үзгәрүе, СССР чорында заман героена әйләнгән Шураның сәхнә тотуы, «стиляга»ларның килеп чыгуы – һәммәсе тарихи фактлар.

Европа, Көнбатыш йогынтысы, дип сөйләшсәк тә, без әле алар кебек үк булдыра алмыйбыз. Татарда Принс, Джеффри Стар, Джаред Лето, Шура, Борис Моисеев, Сергей Зверев кебек «кыю ирләр», һәрхәлдә, эстрадада бик күренми. Юк, дип тә әйтә алмыйбыз.

Хәер, Россиянең халык артисты, Казан дәүләт консерваториясенең вокал сәнгате кафедрасы мөдире Зилә Сөнгатуллина сүзләренчә, эстрада сәнгатенең үз таләпләре бар.

– Артистлар дөньясы шундый инде ул. Әйтик, безнең консерваториядә сәхнә гримы буенча аерым дәресләр бар.

pixabay.com

Экранның, сәхнәнең үзенчәлекләрен исәпкә алып чак кына бизәнү – тиешле әйбер. Якты утлар астында йөзеңне югалтмас өчен кирәк бу. Ләкин ир-атлар өчен сәхнә гримының чик-чамасы бар. Ул табигый булырга тиеш. Ирләргә хатын-кызлар кебек бизәнү – бөтенләй килешә торган әйбер түгел. Ир-егетлек дигән төшенчә бар. Ирләр – безнең таяныч, элек-электән шулай булган бит инде, – диде ул. – Россиядә традицияләргә зур әһәмият бирелә. Бигрәк тә, гаилә, ир-ат һәм хатын-кыз мөнәсәбәтләрендә. Чит ил йогынтысы астында без үз принципларыбызны югалтырга тиеш түгел.

Татарстанның халык артисты Рөстәм Закиров исә ир-атларның пиджак-чалбары үтүкләнсә дә җитә, дигән фикердә.

– Мин авыл гыйбаты булып калдым бугай инде – сәхнәгә бер дә бизәнеп чыкканым юк *(көлә)*. Профессиональ яктан дөрес эшләмимдер, ләкин ир-атларның бизәнүенә кул куя алмыйм. Үз-үзеңне карап йөрсәң яхшы инде, билгеле. Тамашачы алдына чиста, пөхтә, үтүкләнгән костюмнан чыгу – тиеш әйбер. Ир-атлар хәзер прическага да бик игътибар итә бит. Анысын ясар идем дә – чәч калмады *(көлә)*. Артыгын кыланган ир-атлар яшәүләренең кызыгы калмаганга кызык эзләп йөри микән соң инде, читтән кергән гадәтме – белмим. Әмма бер дә безнең халыкка туры килми, – диде ул.

Белгеч фикере

Зөһрә КӘРИМОВА, практик психолог:

– Хәзер күп кенә ирләр хатын-кыз итәгенә ябышуны кулайрак күрә. Шул рәвешле алар ир-егетлек сыйфатларын җуя. Бу – аларның кершән, сөрмәгә тартылуының бер сәбәбе. Икенчедән, хәзерге хатын-кызлар таләпчән түгел, теләгән әйберләрен сорый белмиләр. Өченчедән, үзен хөрмәт иткән, үз ихтыяҗларын төгәл белгән ир-ат мондый адымга бара алмас иде. Бизәнеп йөрү ир-атларга хатын-кызлар тарафыннан наз, мәхәббәт җитмәүне дә аңлатырга мөмкин. Шуны аңларга кирәк: без Ходай тарафыннан бирелгән тышкы кыяфәтебезне кабул итеп, үзебезне яратып яшәргә тиеш.

Яшь җырчы Азат Абитов, беренче мәлләрдә сәер тоелса да, хәзер тамашачы алдына кершән сөртеп чыгуны гадәти әйбер буларак кабул итә икән:

– Безнең эстрадада артык бизәнүче ирләр юк кебек. Съемкалар вакытында кершәнне генә барыбыз диярлек сөртә. Ул экраннан караганда бит тиресе ялтырамасын өчен кирәк. Башта сәер тоела иде. Соңыннан, телевизордан йөзнең ямьсез булуын үз күзләрең белән күргәч, кершәннең бик кирәк булуын аңлыйсың. Ә калганын белмим – сөртеп караганым юк.

Марсель Вагыйзов, бизәнүче генә түгел, хатыны белән бертөрле киенүче ир-атларны да аңламавын әйтте.

– Аллаһы Тәгалә ничек яраткан, син шундый булып калырга тиеш. Йөз-кыяфәтне ничек тә булса үзгәртүгә мин, гомумән, каршы. Ул бит – кешене, тамашачыны алдау дигән сүз. Хатын-кызларның бизәнүе – аерым мәсьәлә инде, ә ир-атларга нигә кирәк бу? Коръәндә бит ир-атлар – хатын-кызларга, хатын-кызлар ир-атларга охшарга тырышырга тиеш түгел, дип язылган, моның өчен җәза каралган. Бизәнеп кенә калмыйча, хатыны кебек киенүче ирләр дә бар бит. Кыскасы, Европада булган бөтен тәрбиясезлекне үзләштереп бетерәбез бугай инде, – дип сөйләде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7043 данә
Гомуми тираж – 18156 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 207

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+